ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО БИОЛОГИЧЕСКИМ РЕСУРСАМ
ул. Карима Тинчурина, д. 29, г. Казань, 420021

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИОЛОГИК РЕСУРСЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ
К. Тинчурин ур., 29 йорт, Казан шәһәре, 420021

Телефон:(843)211-66-94, факс:(843)211-66-47, E-Mail:ojm@tatar.ru, сайт:http://ojm.tatarstan.ru

Приказ г. Казань Боерык

30.11.2020 № 365- од

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2020 елның 17 нче апреленнән 118-од номерлы боерыгы белән расланган, Производство аучылык инспекторы таныклыгын һәм күкрәк билгесен бирү, алмаштыру, мондый таныклыкны гамәлдән чыгару буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының дәүләт хезмәтен күрсәтү эшен камилләштерү максаты белән боерам:

1. Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2020 елның 17 нче апреленнән 118-од номерлы боерыгы белән расланган, Производство аучылык инспекторы таныклыгын һәм күкрәк билгесен бирү, алмаштыру, мондый таныклыкны гамәлдән чыгару буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына киләсе үзгәрешләрне кертергә:

1 нче бүлектә:

1.3.5 пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Комитетның мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү биналарындагы мәгълүмати стендларда урнаштырылган мәгълүмат, Татарстан Республикасының дәүләт телләрендә урнаштырыла һәм үз эченә дәүләт хезмәте турында әлеге Регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3 - 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 нче пунктларда күрсәтелгән мәгълүматны ала»;

1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге, аларның реквизитларын һәм чыганакларын күрсәтеп, Комитетның рәсми сайтында(http://ojm.tatarstan.ru), «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры»

(frgu.tatar.ru )дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган;

1.5 пунктында:

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкнең читтән торып эш урыны- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 22 декабреннән «Күп функцияле үзәкләр тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү эшчәнлегенең кагыйдәләрен раслау турында»гы 1376 нчы карары белән расланган , Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру Кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы муниципаль районының шәһәр округы яки яки шәһәрдә (авыл җирлегендә) төзелгән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкнең территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офис).»;

сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гариза астында дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мөрәҗәгать аңлашыла («Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба - 210-ФЗ номерлы Федераль закон) 2 ст.1 п.). Гаризаларның тәкъдим ителә торган формалары әлеге Регламентның 1,2,5 нче кушымталарында китерелгән.»;

2 нче бүлектә:

2.1 пунктның «Дәүләт хезмәтен яисә таләбен билгели торган норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2009 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 34 статьясы (алга таба - 209-ФЗ номерлы Федераль закон);

Россия Федерациясе Табигый байлыклар һәм экология министрлыгының «Производство аучылык инспекторы таныклыгын һәм күкрәк билгесен бирү, алыштыру, кире кайтару, мондый таныклыкны гамәлдән чыгару тәртибен раслау турында» гы 2014 елның 9 гыйнварындагы 5 номерлы боерыгы белән расланган, производство аучылык инспекторы таныклыгын һәм күкрәк билгесен бирү, алыштыру, кире кайтару, мондый таныклыкны гамәлдән чыгару тәртибе (алга таба - Тәртип)»;

2.2 пунктның «Дәүләт хезмәтен яисә таләбен билгели торган норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 15 декабрендәге 996 номерлы «Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре турында»гы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмәнең 4.1.46 пункты »;

2.6 пунктның «Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына куелган таләпләр исеме» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнары яки

җирле үзидарә органнары карамагындагы оешмаларда булган һәм мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге, шулай ук аларны мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны бирү тәртибе».

2.8 пунктның «Стандартка куелган таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәтен туктатып тору өчен нигезләр:

Комитетка производство аучылык инспекторы кандидатларына карата таләпләрне белүне уңышлы үткән затларның фотосурәтләрен һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән тиешле документларны тапшырмау.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез:

производство аучылык инспекторы кандидатларына карата куелган таләпләрне белүгә уздырылган тикшерүне уңышлы уза алмау.»;

2.8 пунктның «Дәүләт хезмәтен яисә таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Тәртипнең 13, 17, 32 пунктлары»;

2.12 пунктта:

«Стандартка куелган таләпләр эчтәлеге» графасының икенче абзацында «дәүләт хезмәтен алучылар» сүзләрен «мөрәҗәгать итүчеләр» сүзләренә алмаштырырга;

«Дәүләт хезмәтен яисә таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы Указының 1 п.;

2.14 пунктының «Стандартка куелган таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәтен күрсәтү, янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган комитетның бинасында һәм бүлмәләрендә тормышка ашырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен җайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла.

Инвалидларга, шул исәптән кресло-коляскадан һәм этләрдән файдалана торганнарга, бинадан һәм хезмәт күрсәтүләрдән файдалану мөмкинлеген тәэмин итү буенча чаралар гамәлгә ашырыла:

бинага һәм бүлмәләргә, шулай ук аларда күрсәтелә торган хезмәтләргә тоткарлыксыз керү шартлары;

Комитет территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү, Комитет бинасына керү һәм аннан чыгу, транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып;

күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт функциясе бозылуга ия булган инвалидларны

озатып бару һәм аларга бинада һәм бүлмәләрдә ярдәм күрсәтү;

инвалидларның чикләүләрен исәпкә алып, биналарга, бүлмәләргә һәм хезмәт күрсәтүгә тоткарлыксыз үтеп керә алуын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүматларны җайлы итеп урнаштыру;

инвалидлар өчен кирәкле тавыш һәм язма мәгълүматны, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм башка текст һәм график мәгълүматны Брайльнең рельеф-нокталы шрифты белән башкарылган билгеләр белән кабатлау, сурдотәрҗемәчене һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертү;

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Озатучы этнең махсус укытуын раслый торган документ формасын һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган форма һәм тәртиптә бирелә һәм махсус укытуны раслый торган документ булган очракта, бинага һәм бүлмәләргә, озатучы этне кертү;

хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга, башка затлар белән беррәттән, хезмәт алырга комачаулаучы киртәләрне үтәргә ярдәм итү.

Инвалидлар өчен дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның үтемлелеген тәэмин итү өлешендә таләпләр, 2016 елның 1 июленнән соң файдалануга тапшырылган, капиталь ремонт, үзгәртеп корылган, модернизация узган объектларга карата кулланыла.».

2.14 пунктның «Хезмәт күрсәтүне яисә таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы»;

3 нче бүлектә:

3.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5. Административ процедураны башлау өчен нигез булып, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар комплектын теркәү тора.

Вазыйфаи зат кергән документлар комплектындагы белешмәләрнең тулылыгын һәм дөреслеген тикшерә.

Вазыйфаи зат, бирелгән гаризаларда күрсәтелгән мәгълүматны, Комитетта производство аучылык инспекторы вазыйфасына таләпләрне белүен тикшерүне уңышлы узган кандидатларга карата булган мәгълүмат белән чагыштыра.

Әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән шартлар булганда, вазыйфаи зат, документлар комплекты алынган көнне, производство аучылык инспекторы таныклыгын һәм күкрәк билгесен бирүдән баш тарту турында белдерү проекты (алга таба – проект) әзерли һәм проектлардагы белешмәләрдә төгәлсезлекләр һәм хаталар булмаган очракта, аны Комитет рәисенә яки аның вазыйфаларын башкаручы затка имза кую өчен тапшыра.

Производство аучылык инспекторы таныклыгын һәм күкрәк билгесен бирүдән баш тарту турындагы белдерү шәхсән яки почта аша (шул исәптән электрон почта аша) бирелә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән административ процедураны гамәлгә ашыру вакыты,Комитетка таныклык һәм производство аучылык инспекторының күкрәк

билгесе һәм аңа кушып бирелә торган документларны бирү турындагы гариза кергән көннән алып, өч эш көне тәшкил итә.

Административ процедураның нәтиҗәсе булып, гариза бирүчегә, Россия Федерациясе законнары нигезендә аның шәхесен таныклаучы документ күрсәтүче, гариза бирүче булмаган производство аучылык инспекторына производство аучылык инспекторы таныклыгын һәм күкрәк билгесен бирүдән баш тарту турында бирелгән (җибәрелгән) хәбәрнамә тора.»;

5 нче бүлектә:

бүлекнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең, Федераль законның 16 статьясындагы $1^1$ бүлегендә күрсәтелгән оешмаларның, ә шулай ук аларның вазыйфаи затларының һәм дәүләт хезмәткәрләренең карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе.»;

5.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.6. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан аның дәлилләрен раслаучы документлар (яисә аларның күчермәләре) тапшырылырга мөмкин.».

2. Рәис урынбасарларына, структур бүлекчәләр җитәкчеләренә, дәүләт хезмәте күрсәтүне турыдан-туры тәэмин итүче затларга Регламент нигезләмәләрен үтәүне һәм аның тарафыннан каралган тиешле документларны алып бару тәэмин итәргә.

3. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип танырга.

Рәис Ф. С. Батков